

Ләмберә авылы моселманнары очен 1998 елнын 28нче январендә мәчет ачылды. Изге йорт рухи камиллек, гүзәллек нигезендә тозелде. Мәчетнен тозелешен олы тарихи бер вакыйга дип бәяләргә кирәк. Ул безнен мәнгегә калачак тарихи истәлегебез.
Революциягә кадәр Ләмберәдә дүрт мәчет булган. Ин борынгы урамнардан саналган “Урман очы” дип әйтелгән хәзерге Крестьяннар урамында бер мәчет, Большевиклар урамында ике мәчет булган. “Веселка” урамында (хәзерге Комсомольская урамы) – бер мәчет булган.
Ләмберә авылына беркетелгән авыл муллаларына баш хәзрәт вазифасын үтәгән Камалетдин хәзрәт Усманов, Бәдретдин хәзрәт Яхин, анын уллары: Ахмәт мулла (Яхин Абделәхәт абыйнын әтисе), Сафиулла мулла Яхиннар авыл халкына бик таныш белгечләр. Мәчетләрдә, ойләрдә мәдрәсәләр оештырып авыл халкына дини белем биргәннәр. 17-18 гасырларда Ләмберәдә ике зират бер буй булып сузылып кечрәк кенә тау башына урнашканнар. Беренче иске зиратта кабер ташлары барлыгы да ачыкланды. Кызганычка каршы, иске кечкенә зират мәйданына 80нче елларда, чиновникларнын рохсәте белән, “Яшьләр урамы” (Молодежная) тозелде.
Революциядән сон (25-30нче еллар) авыл мәчетләренен манараларын аударалар, иман йортларын туздырып ташлыйлар. Имам муллаларны авылдан сореп тоткынлыкка озаталар. Большевиклар урамындагы мәчетнен манарасын тошереп анда, 1934нче елда, район газетасы редакциясе оештырыла. Комсомоллар урамындагы мәчеттә башта башлангыч мәктәп, сонга балалар бакчасы ачыла. 1980нче елларга кадәр Комсомоллар урамындагы мәчетнен бүрәнәләре саклана.
Мәчет бурасын сүтеп, хәзерге Ленина урамында нәчәлләргә квартиралар тозиләр. Анда үз вакытында, 1955нче елларда, райисполком председателе Сырмолотов Бясыр Ханяфия улы да яшәде. Крестьяннар урамындагы мәчет 1929нче елда авылда зур янгын вакытында яна. Шундый авырлыкларга карамастан, авылда мәчет урыннары бүгенге конгә кадәр онытылмады. Мәрхүмнарны зиратка озатканда, женазаны мәчет алды мәйданына куеп, картлар дога укыйлар иде. Кызганычка каршы, хәзерге муллалар бу гореф-гадәтләрне үтәмиләр. Авылда туй булганда мәчет урынын атлар белән әкрен генә әйләнеп уза иделәр. Без, сугыш еллары балалары, бу гореф-гадәтләрне гомергә истә

калдырдык.
Советлар заманында Ләмберәдә мәчет булмаса да, кыш айларында авылнын картлары бер ойгә жыелып жомга намазларын, тәрәвих һәм ает намазларын ойләрдә укыдылар. Жәй айларында зират тауы астында укыдылар. Авылны мәчетсез, нурсыз калдырсалар да, авылдашлар күнеленнән иман нурын жуя алмадылар. Крестьяннар урамында яшәүче Каников Нясрулла Исмәтулла улынын оендә 30 еллар чамасы һәр жомга, тәрәвих, ает намазлары укылды. Тәрәзәсе янына балалар да, яшьләр дә “Собхан” тынларга жыела идек. Сугыш елларында намазларны Байбеков Хайрулла оендә укыганнар. Сонга Янгляева Мәрьям Якуб кызынын оендә укытылды.
Ләмберә авылынын дүрт мәчетендә дүрт имам торган. Крестьяннар урамы мәчете имамы Ахмәт мулла Яхин була. Сафиулла мулла Яхин Комсомоллар урамы мәчете имамы була. Большевиклар урамы мәчетләрендә имам булып Усманов Камалетдин хәзрәт һәм Рәхимов Летфулла була. Яхиннар гаиләсендә оч мулла. Бәдретдин хәзрәт ул елларда бакыйлыкка күчә. Ахмәт мулланын улы Абделәхәт абый мулла вазифасын үтәмәсә дә, Боек Ватан сугышы ветераны буларак 87 яшендә биш намазын укып бүгенге тозелгән мәчеткә, ислам юлында күп изгелекләр эшләде.
Шулай итеп, 30нчы елларда мәчет-ләребез беттеләр. Имамнарыбыз тоткынлыкта югалдылар. Әммә Ләмберә имамнарыбызнын истәлеге булып бер изге әйбер бүгенге конгә кадәр сакланып калды. Ул әйбер – Бәдретдин хәзрәтнен хотбә таягы. Бу таякны Бәдретдин хәзрәткә 19нчы гасырнын ахырында Ләмберә авылы аша узып баручы хажиләр калдырган. Бу хажиләр Сергач яклары кешеләре булгандыр. Алар үз якларына Мәккәдән кайтканда, Ләмберә мәчетенә кереп, намаз укып, үзләре белән изге шәһәрдән китергән хотбә таягын Бәдретдин хәзрәткә бүләк итеп биргәннәр. Муллаларны мәчетләрдән куып, мәчетләр ябылгач, Бәдретдин хәзрәт хотбә таягын улына, Сафиулла муллага бирә. 1929нче елда ике туган Ахмәт һәм Сафиулла муллаларны, яшьләр белән дини дәресләр алып барган очен, тоткынлыкка ябалар. Сафиулла мулла хотбә таягын Хайрулла муллада калдыра. Хайрулла мулла мәрхум булгач, хотбә таягы Рәхимов муллада кала. Ул елларда намазлар Янгляева Мәрьям апанын оендә укыганлыктан, таяк шул ойдә сакланып кала.
Буыннан буынга күчеп барган бу хотбә таягынын яше 100дән артканлыктан ул кибеп, яргаланып, очлары тетелеп бетә.
Ләмберәдә 1998нче елны яна мәчет ачылуга таякны Мәрьям апа (Боек Ватан сугышы ветераны) Мәскәүгә реставрациягә жибәрә. Бу легендар таяк Мәскәүдән айлы булып Ләмберәгә кайтты. Янартылган хотбә таягын, изге теләкләр белән, Ләмберәдә 28нче январь конне яна мәчет ачылганда Ләмберәнен имамы Наиль Юсуповка тапшырдык.
Ике туган Ахмәт һәм Сафиулла муллаларга авылга кайтырга нәсыйп булмады. Ахмәт мулла тоткынлыкта югалды, Сафиулла мулла Ярославль шәһәрендә сонгы гомерен кичерде. Шул ук 1929нче елда Камалетдин хәзрәтне, хатыны белән, кулга алалар. Алар икесе дә тоткынлыкта һәләк булалар.
1955-1997 елларда Ләмберәдә имам вазифалалын үтәгән изге жаннарны искә алыйк: Фазлов Хайрулла, Фазлов Сәнәтулла, Рәхимов Летфулла, Фазлов Садыйк, Биктеев Ахмәт, Бикчурин Алиулла.
Ләмберә авылында яшәүче моселманнарнын уртак ризалыгы, хәер-фатихасы белән жиде ел тозелгән куркәм эшнен нәтижәсе күнелләргә иман нуры, ойләргә ислам рухы индерде. Авылда ислам дине янадан торгызыла. Ул икенче яшьлеген кичерә.
Бу мәчетне тозүдә ярдәм иткән Ләмберә авылынын булдыклы, шәфкатьле кызы Галия

Котиковага зур рәхмәт. Бүгенге мәчетнен исеме дә “Галия” мәчете дип атала. Мәчетнен түбәсен үз малына тимер белән каплаучы эшмәкәр, Мордовия татарларынын аксакалы Шамиль Зәкәрия улы Бикмаевка зур рәхмәтләрне юллыйбыз. Мәчет мәйданына һәм зират юлына асфальт жәйдерүче Ләмберә авылынын булдыклы егете Шамиль Анвәр улы Салимовка, тумышы белән Хаджи авылында үскән егетебез Равиль Курмакаевка, Ләмберә егете Марс Авязовка, ботен авыл халкына, Ләмберәдә яшәүче үзгә милләт кешеләренә, Ләмберәнен ботен моселманнары исеменнән саулыклы, бәхетле тыныч гомер юллары теләп калабыз.

Рәшидә Ипкаева